ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 август 2019 ел № 4410

Башкарма комитетның «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 21 апрелендәге 1964 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда гражданнарга өстәмә гарантияләр билгеләү өлешендә 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ санлы Федераль закон нормаларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм үз көчен югалтуны тану турында» 2018 елның 21 декабрендәге 1622 нче карарына туры китерү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 21 апрелендәге 1964 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3278 нче, 2017 елның 4 сентябрендәге 5126 нчы, 2018 елның 9 июнендәге 3335 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карары белән» сүзләрен «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге белән» сүзләренә алмаштырырга»;

2) адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- 1.5 пунктның 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «планлаштыру структурасы элементы – гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бара торган зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), территориясе;»;

- 2.3 пунктында «үзгәрешләр яки» сүзләрен алырга;

- 3 бүлекне 1 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

- 4.4 пунктының икенче абзацында «кисәктә» сүзен «бүлектә» сүзенә алмаштырырга;

- 5 бүлекне 2 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

- 2 нче кушымтаны әлеге карарга 3 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

- 3 нче кушымтаны әлеге карарга 4 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

- 4 нче кушымтаны әлеге карарга 5 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

- әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә 5 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның
28 августындагы
4410 нчы карарына
1 нче кушымта

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органга (оешмага) җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эш итүләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турындагы консультацияләрне шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша алу өчен Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалануның составы, тапшырыла торган документларның формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруга ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәттән файдалануның составы, тапшырыла торган документларның формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануда башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача рәвештә гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза электрон рәвештә Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең әлеге Регламентның 1.3.3. пунктында күрсәтелгән электрон почтасына җибәрелә.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен аныклый;

гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) вәкаләтләрен тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә (документ күчермәләренең тиешенчә тутырылуы, документларда чистартулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр булу) туры килүен тикшерә.

Кимчелекләр булмаган очракта, Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә гаризаның күчермәсен һәм документларны кабул итү датасы, теркәгәндә бирелгән номеры, муниципаль хезмәт күрсәтүне үтәү датасы һәм вакыты турында билге куелган опись күчермәсен бирә.

гаризаны карау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Документлар кабул итүне кире кагу өчен Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документлар кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гариза кабул итү – 15 минут эчендә.

Гаризаны теркәү – гариза кергәннән башлап бер эш көне эчендә. Электрон рәвештә эш көне тәмамланганнан соң яки бәйрәм көннәрендә кергән гариза алдагы эш көненең беренче сәгате эчендә теркәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, карау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән, яки гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карый һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрелгән гариза.

3.3.4. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары гаризаны карый һәм Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгына җибәрелгән гариза.

3.3.5. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы гаризаны карый һәм аны Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгеченә җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) җибәрү.

3.4.1. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) (алга таба – мәгълүмат куючылар) әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны (мәгълүматны) тапшыру турында ведомствоара запросларны (кәгазь йөрткечтәге яки ведомствоара электрон эшчәнлек системасы аша электрон рәвештәге документны) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгеченә гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: органнарга (оешмаларга) җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат куючы белгечләр, кергән запрослар нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон эшчәнлек системасы аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки документның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәр итү кәгазе җибәрәләр (алга таба – документның (мәгълүматның) булмавы турында хәбәр итү кәгазе).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар ведомствоара запросның документ (мәгълүмат) бирүче органга (оешмага) кергән көненнән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм Татарстан Республикасының федераль законнар нигезендәге норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүмат) яисә документның (мәгълүматның) булмавы турында хәбәр итү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) гаризага теркәлгән документлардагы мәгълүматларның документта (мәгълүматта) яисә мәгълүмат куючыларның документның (мәгълүматның)

булмавы турындагы хәбәр итү кәгазендә бәян ителгән мәгълүматларга туры килүен тикшерә;

2) карар проектын әзерли:

- әлеге Регламентның 2.9 пунктына каралган муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр булганда, объектка адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгаруны кире кагу турында (алга таба – кире кагу турында карар проекты);

- әлеге Регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча объектка адрес бирү (гамәлдән чыгару) турында (алга таба – карар проекты);

Әлеге пунктның беренче һәм икенче пунктчаларында билгеләнгән процедуралар мәгълүмат куючылардан документ (мәгълүмат) алынган вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3) карар проектын килештерә:

- кире кагу турында карар проектын – Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы, аннары Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, аннары Хокук идарәсе башлыгы, аннары Башкарма комитет аппараты Җитәкчесе белән;

- карар проектын – Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы, аннары Хокук идарәсе башлыгы, аннары Башкарма комитет аппараты Җитәкчесе белән.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

4) карар проекты имзалауга җибәрелә:

- кире кагу турында карар проекты – Башкарма комитет Җитәкчесенә;

- карар проекты – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына.

Әлеге да билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалауга җибәрелгән карар проекты.

3.5.2. Кире кагу турында карар проектының – Башкарма комитет Җитәкчесе, карар проектының Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзалау һәм имзаланган карар проектын теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен җибәрелгән карар проекты.

3.5.3. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) имзаланган карар проектын теркәү журналында терки;

2) Башкарма комитетның теркәлгән карары күчермәләрен тарату реестры нигезендә бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тарату реестры нигезендә бирелгән Башкарма комитетның теркәлгән карары күчермәләре (алга таба – муниципаль хезмәт нәтиҗәсе).

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә), гаризада күрсәтелгән элемтә алымын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында, аны бирүнең датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.6.2. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче үзе килгән очракта – 15 минут эчендә.

3.7. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәкләр аша күрсәтү

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Күпфункцияле үзәк аша муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптәге эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Күпфункцияле үзәктән муниципаль хезмәттән файдалану өчен документлар кергәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8. Техник хаталарны төзәтү

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата табылган очракта, гариза бирүче Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 5 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документ;

техник хата булуны дәлилләүче, юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (аның вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтаны кулланып), яисә РФ ның бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, ТР ның бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки КФҮ аша.

3.8.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, гаризаны теркәлгән документлары белән терки һәм аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә карау өчен җибәрелгән гариза.

3.8.3. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә. Процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3, 3.3.4 һәм 3.5 пунктларында каралганча гамәлгә ашырыла.

Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе белгече муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә үзгәрешләр кертү турында Башкарма комитет карарын гариза бирүчегә (аның вәкиленә) шәхсән, гариза бирүчедән (аның вәкиленнән) техник хата булган документның төп нөсхәсен кире алмыйча гына, имза куйдыртып бирә, яки гариза бирүченең адресына почта аша (электрон почта аша) техник хатаны төзәтү турындагы документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедура җибәрелгән хата турында теләсә нинди кызыксынган заттан гариза кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында гариза бирүчегә бирелгән документ.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 28
августындагы
4410 нчы карарына
2 нче кушымта

## 5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүче Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, комплекслы запросны теркәү срогы бозылу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылу.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документлар һәм мәгълүмат яисә эш итүләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигез федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки

муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта, гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә, яисә 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсенең 1 бүлегендәге 4 пунктында каралган очраклардан кала, муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәкле, булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге кабул итүне беренчел кире какканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

Күрсәтелгән очракта, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең,

күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон төрдә Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), шулай ук 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларга бирелә.

Башкарма комитет Җитәкчесенең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр Яр Чаллы шәһәренең Шәһәр Советына бирелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр шул күпфункцияле үзәкнең җитәкчесенә бирелә.

Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яки Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән вәкаләтләнгән вазыйфаи затка бирелә.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр шул оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

Әлеге Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен

телефон номеры (лары), электрон почта адресы (лары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

Гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.4. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә.

Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокуый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

5.7. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап, әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон төрдә җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгәнчә, гариза бирүчегә, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне кичекмәстән бетерү максатында, Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның

гамәлгә ашырылган эш итүләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдаланганда гариза бирүчегә кирәкле булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе, ачыкланган кимчелекләрне бетерү һәм булдырмау максатында кабул ителергә тиешле чараларны билгели.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгәнчә, гариза бирүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатма бирелә.

5.11. Шикаятьләрне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар составы яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 28 августындагы
4410 нчы карарына
3 нче кушымта

Адреслар бирү, үзгәртү һәм
гамәлдән чыгару буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эш итүләр эзлеклелегенең блок-схемасы




АШТ һ ТҮИ белгече гаризаны карый, формалаштыра һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны (мәгълүматны) тапшыру турында запрослар җибәрә
Мәгълүмат куючыларга җибәрелгән запрослар
Мәгълүмат куючы белгечләр запрослар нигезендә соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр
АШТ һ ТҮИ белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүмат)
АШТ һ ТҮИ белгече кергән документлар (мәгълүмат) нигезендә карар проектын әзерли һәм аны Хезмәт регламентында билгеләнгән тәртиптә килешенүгә җибәрә
Килешенүгә җибәрелгән карар проекты
АШТ һ ТҮИ белгече килешенгән карар проектын имзалауга җибәрә
Имзалауга җибәрелгән, килешенгән карар проекты
Карар проектын имзалау һәм аны теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрү
Теркәү өчен җибәрелгән карар проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече имзаланган карар проектын терки һәм тарату реестры нигезендә күчермәләрен җибәрә
Теркәлгән, тарату реестрына җибәрелгән Башкарма комитет карары

АШТ һ ТҮИ белгече гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең әзерлеге турында хәбәр итә һәм ул килгән вакытта Башкарма комитет карарын бирә

↓

Башкарма комитетның гариза бирүчегә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 28 августындагы
4410 нчы карарына
4 нче кушымта

Муниципаль хезмәтләр күрсәтү,
адреслар бирү, үзгәртү һәм
гамәлдән чыгару буенча
административ регламентка
5 нче кушымта

Адреслы объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгаруны кире кагу турында карарның формасы[1]

______________________________________

______________________________________
(гариза бирүченең (вәкиленең) Ф.И.А.и., адресы)

______________________________________
(адреслы объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгару турындагы гаризаны теркәү номеры)

Адреслы объектка адрес бирү яки аның адресын юкка чыгаруны кире кагу турында карар
(кирәк түгелен сызарга)

...
№ (датасы)

______________________________________________________________

______________________________________________________________
(җирле үзидарә органының исеме)

хәбәр итә. ______________________________________________________,
(гариза бирүченең Ф.И.А.и. юнәлеш килешендә, шәхесен таныклаучы документның исеме, номеры һәм бирү вакыты

______________________________________________________________
физик затлар өчен – почта адресы; тулы исеме, ИНН, КПП (Россиядә яшәүче юридик затлар өчен)

______________________________________________________________
иле, теркәү вакыты һәм номеры (чит илнең юридик заты өчен), юридик зат өчен – почта адресы)

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 нче карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре нигезендә түбәндәге адреслы объектка адрес бирү (юкка чыгару) кире кагыла (кирәклесенең астына сызарга)

[1] Башкарма комитет бланкында тутырыла

(адреслы объектның төре һәм исеме, гариза бирүченең адреслы объектка адрес бирүне сорап мөрәҗәгать иткәндә адреслы объектның урыны тасвирламасы)

гариза бирүченең адреслы объектның адресын юкка чыгаруны сорап мөрәҗәгать иткән очракта объектның адресы)

бәйле рәвештә

.

(кире кагу Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 нче карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләренең 40 нчы пунктына нигезләнә)

Җирле үзидарә органы
вәкаләтле затының
вазыйфасы

(имза) (имза расшифровкасы)

М.У.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 28 августындагы
4410 нчы карарына
5 нче кушымта

Муниципаль хезмәтләр күрсәтү,
адреслар бирү, үзгәртү һәм
гамәлдән чыгару буенча
административ регламентка
4 нче кушымта

Адрес бирү турында карарның формасы[2]

Адрес бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 бүлекнең 27 пункты, Россия Федерациясенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 нче карары белән расланган адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре, Башкарма комитет карары белән расланган адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә, (гариза бирүченең Ф.И.А.и. күрсәтергә) гаризасын караганнан соң

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Кадастр номерлы (күрсәтергә) җир участогына адрес бирергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәр округы, Яр Чаллы шәһәре, планлаштыру структурасы элементының исеме (булганда), урам-юл челтәре элементының исеме (булганда), җир участогының номеры[3].

Кадастр номерлы (күрсәтергә) җир участогында урнашкан кадастр номерлы (булганда күрсәтергә) адреслы объектка (булганда исеме) адрес бирергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәр округы, Яр Чаллы шәһәре, планлаштыру структурасы элементының исеме (булганда), урам-юл челтәре элементының исеме (булганда), бинаның, корылманың яки тәмамланмаган төзелешнең типы һәм номеры[4].

Нәтиҗәдә барлыкка килгән кадастр номерлы (күрсәтергә) бинада (корылмада) урнашкан адрес объектына (булганда исеме, мәйданы кв.метрларда) адрес бирергә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәр округы, Яр Чаллы шәһәре, планлаштыру структурасы элементының исеме (булганда), урам-юл челтәре элементының исеме (булганда), бинаның, корылманың типы һәм номеры, бина эчендәге бүлмәләрнең типы һәм номеры, фатир эчендәге бүлмәләрнең типы һәм номеры (коммуналь фатирлар өчен[5]).

---

[2] Башкарма комитет бланкында тутырыла
[3] Җир участогына адрес биргәндә
[4] Бинага, корылмага яки төзелеп бетмәгән объектка адрес биргәндә
[5] Бина (корылма) эчендәге бүлмәләргә адрес биргәндә

2. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә:

1) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән адреслы объектның адресы турындагы мәгълүматны дәүләт адрес реестрына урнаштырырга;

2) (гариза бирүченең Ф.И.А.и. күрсәтергә) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән адреслы объект фасадына Башкарма комитетның 2019 елның 28 августындагы 4410 нчы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карары белән расланган үрнәктәге адреслы аншлаг куярга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җирле үзидарә органы вәкаләтле
затының вазыйфасы

(имза) (имзаның расшифровкасы)

Адресны гамәлдән чыгару турындагы карарның формасы[6]

Адресны гамәлдән чыгару

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 нчы маддәсендәге 1 нче бүлекнең 27 нче пункты, Россия Федерациясенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 нче карары белән расланган Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләре, Башкарма комитет карары белән расланган адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә, (гариза бирүченең Ф.И.А.и. күрсәтергә) гаризасын караганнан соң
(адресны гамәлдән чыгаруның сәбәбен күрсәтергә)

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның (дата) № (саны) карары белән бирелгән кадастр номерлы, дәүләт адрес реестрында уникаль номеры булган (уникаль номерны күрсәтергә) адреслы объектның адресын гамәлдән чыгарырга[7]: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәр округы, Яр Чаллы шәһәре, планлаштыру структурасы элементының исеме (булганда), урам-юл челтәре элементының исеме (булганда), җир участогының номеры[8],бинаның, корылманың яки тәмамланмаган төзелеш объектының типы һәм номеры[9], бина эчендәге бүлмәләрнең типы һәм номеры, фатир эчендәге бүлмәләрнең типы һәм номеры (коммуналь фатирлар өчен[10])

Вәкаләтле орган билгеләгән башка кирәкле мәгълүматлар.

---

[6] Башкарма комитет бланкында тутырыла
[7] Адреслы объектның бетерелүе сәбәпле адреслы объект гамәлдән чыкканда адреслы объектның кадастр номеры һәм кадастр исәбеннән төшерү вакыты
[8] Җир участогын гамәлдән чыгарганда
[9] Җир участогының адресы юкка чыгарылганда
[10] Бина (корылма) яки төзелеп бетмәгән объектның адресы юкка чыгарылганда

2. Башкарма комитетның ((датасы) № (саны) «Исеме» карарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә әлеге карарны дәүләт адрес реестрына кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җирле үзидарә органы вәкаләтле
затының вазыйфасы

(имза) (имза расшифровкасы)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 28 августындагы
4410 нчы карарына
6 нчы кушымта

Муниципаль хезмәтләр күрсәтү,
адреслар бирү, үзгәртү һәм
гамәлдән чыгару буенча
административ
регламентка
5 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында гариза формасы

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесе

________________________________________
(Ф.И.А.и.)
______________________________________
________________________________________
(физик зат өчен: фамилиясе, исеме һәм (булганда) атасының исеме, гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документның реквизитлары;

юридик зат өчен: гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затның дәүләт теркәве язуының дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификацион номеры, гариза бирүче чит илнең юридик заты булмаган очраклардан кала)

________________________________________
________________________________________
(гариза бирүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм____
____________________________________________________________________________
(муниципаль хезмәтнең исеме)

Язылган:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу карары кабул ителсә, ул карарны электрон документ рәвешендә
түбәндәге адреска җибәрүне сорыйм: E-mail: ___________________;
кәгазь йөрткечтәге расланган күчермәне почта аша җибәрү адресы:
_______________________________________________________________________________.

Үземнең, шулай ук минем вәкилнең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирәм (муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны җыю, системага салу, туплау, саклау, төгәллек кертү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән бирү), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокировкалау, шәхси мәгълүматларны юкка чыгару, шулай ук башка гамәлләрне башкару), муниципаль хезмәт күрсәтү органының алар нигезендә автоматлаштырылган режимда муниципаль хезмәт күрсәтү максатында карарлар кабул итүен дә кертеп.

Минем шәхесемә һәм минем вәкил булган затка караган, гаризага кертелгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм. Гаризага беркетелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә, әлеге документлар гариза язган вакытка гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларга ия.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалык бирәм: ________________.

| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
|---|---|---|
| гариза бирүченең вазыйфасы (юридик зат өчен) | (имза) М.У. | (Ф.И.А.и.) |

«____» _________20__

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова